СОВЕТ НОВОАКСУБАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКСУБАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Центральная, д.31,
с.Новое Аксубаево, 423070

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА АКСУБАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Үзек урам,31 енче йорт
Яңа Аксубай авылы , 423070

Тел.: (84344) 4-20-47, факс: (84344) 4-20-47. E-mail:Naks.Aks@tatar.ru , http://aksubayevo.tatarstan.ru

КАРАР

№ 28 2021 елның 25 мае

**«Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яна Аксубай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 28 февралендәге 61 номерлы Яна Аксубай авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Норматив хокукый актларны законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Яна Аксубай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Аксубай муниципаль районы Яна Аксубай авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Яна Аксубай авыл җирлеге Советының 2018 елның 28 февралендәге 61 номерлы карарына «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яна Аксубай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләрен раслау турында»:

- 13 абзацта 125 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «-тиешле тәртиптә төзелгән һәм дәүләт кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләре милекчеләре өчен, әгәр бу Россия Федерациясе законнарында каралган мәҗбүри таләпләрне бозмаса, аларда стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында карар кабул итү мөмкинлеге тулысынча юкка чыгарылырга тиеш»

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам

Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе А.В.Макаров